**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 12 февраль № 90

г. Казань

Татарстан Республикасында транспорт чараларын газ-мотор ягулыгына күчерүне гамәлгә ашырган юридик затларга, индивидуаль эшмәкәрләргә һәм физик затларга чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2013-2023 елларга Татарстан Республикасында газ-мотор ягулыгы базарын үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 26 апрель, 283 нче карары белән расланган «2013-2023 елларга Татарстан Республикасында газ-мотор ягулыгы базарын үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасы чараларын тормышка ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасында транспорт чараларын газ-мотор ягулыгына күчерүне гамәлгә ашырган юридик затларга, индивидуаль эшмәкәрләргә һәм физик затларга чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен (карарга теркәлә) расларга.
2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы А.В.Песошин

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 12 февраль, 90 нчы карары белән расланды

**Татарстан Республикасында транспорт чараларын газ-мотор ягулыгына күчерүне гамәлгә ашырган юридик затларга, индивидуаль эшмәкәрләргә һәм физик затларга чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе**

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасында транспорт чараларын газ-мотор ягулыгына күчерүне гамәлгә ашырган юридик затларга, индивидуаль эшмәкәрләргә һәм физик затларга чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр (алга таба – субсидияләр) бирү кагыйдәләрен һәм шартларын билгели.

1.2. Субсидияләр тиешле финанс елына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законында каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2013-2023 елларга Татарстан Республикасында газ-мотор ягулыгы базарын үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 26 апрель, 283 нче карары белән расланган «2013-2023 елларга Татарстан Республикасында газ-мотор ягулыгы базарын үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасы чарасын тормышка ашыру максатларында, билгеләнгән тәртиптә бирелә.

1.3. Әлеге Тәртиптә файдаланыла торган төп төшенчәләр:

Вәкаләтле орган – Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы;

Вәкаләтле оешма – үзенең эшчәнлеген Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының эшмәкәрлеккә булышлык күрсәтү үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе тибын үзгәртү юлы белән «Татарстан Республикасының кече һәм урта эшмәкәрлеккә булышлык күрсәтү һәм аны үстерү программаларын тормышка ашыру үзәге» дәүләт казна учреждениесен оештыру турында» 2015 ел, 4 март, 132 нче карары нигезендә гамәлгә ашыручы «Татарстан Республикасының кече һәм урта эшмәкәрлеккә булышлык күрсәтү һәм аны үстерү программаларын тормышка ашыру үзәге» дәүләт казна учреждениесе;

гариза бирүчеләр – транспорт чараларын газ-мотор ягулыгына күчерүне гамәлгә ашырган юридик затлар, индивидуаль эшмәкәрләр һәм физик затлар;

автомобильләрне яңадан җиһазлау һәм аларга техник хезмәт күрсәтү пунктлары (алга таба – ЯҖТХК пунктлары) – җаваплылыгы чикләнгән «Газпром газ-мотор ягулыгы» җәмгыяте белән партнерлык килешүләре төзегән һәм гариза бирүчеләрнең транспорт чараларын газ-мотор ягулыгына күчерүне гамәлгә ашыручы юридик затлар яки индивидуаль эшмәкәрләр;

шартнамә – транспорт чараларын газ-мотор ягулыгына (метан) күчерү буенча ЯЖТХК пунктлары белән шартнамә (контракт);

килешү – Вәкаләтле оешма һәм гариза бирүче арасында төзелә торган субсидия бирү турында шартнамә.

1.4. Субсидияләр түбәндәге шартларга җавап биргән гариза бирүчеләргә бирелә:

а) Татарстан Республикасы территориясендә теркәлгән булу;

б) эшчәнлекләрен Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә ашыру (юридик затлар һәм индивидуаль эшмәкәрләр өчен);

в) милекчелек хокукында 2016 елның 1 мартыннан башлап ЯЖТХК пунктларында газ-мотор ягулыгына күчерелгән транспорт чарасы булу.

## 2. Субсидия бирүгә документларны әзерләү

2.1. Субсидия алу өчен гариза бирүче Вәкаләтле оешмага түбәндәге документлардан торган заявка кертә:

а) Вәкаләтле орган раслаган форма буенча гариза;

б) Россия Федерациясе гражданы паспорты күчермәсе (физик затлар өчен);

в) уңай карар кабул итү очрагында субсидия күчерелә торган банк исәбе шартнамәсенең банк таныклаган күчермәсе (физик затлар өчен);

г) Россия кредит оешмасында ачылган, уңай карар кабул итү очрагында субсидия күчерелә торган хисап исәбенең банк реквизитлары турында гариза бирүченең җитәкчесе һәм баш бухгалтеры тарафыннан имзаланган белешмә (юридик затлар һәм индивидуаль эшмәкәрләр өчен);

д) газ-мотор ягулыгына күчерелгән транспорт чарасы күчермәсе;

е) транспорт чарасын теркәү шаһәдәтнамәсе күчермәсе;

ж) барлык өстәмә килешүләрне һәм алрга кушымталарны теркәп, шартнамә күчермәсе;

з) шартнамә буенча башкарылган эшләр акты күчермәсе;

и) түләү йөкләмәсе күчермәсе һәм шартнамә яклары үз өсләренә алган йөкләмәләрнең үтәлешен раслый торган башка документлар күчермәләре;

к) җаваплылыгы чикләнгән «Газпром газ-мотор ягулыгы» җәмгыятенең ягулык картасын бирүгә гариза күчермәсе яисә газ баллоны җиһазлары сатып алуга гариза бирүче һәм җаваплылыгы чикләнгән «Газпром газ-мотор ягулыгы» җәмгыяте арасында төзелгән заем шартнамәсе күчермәсе.

2.2. Заявка кәгазьдә тапшырыла.

2.3. Барлык кертелә торган документлар аңлаешлы итеп бастырып чыгарылган һәм бөтен пунктлар буенча тутырылган булырга тиеш (мәгълүматлар булмаганда сызык куела). Мөһер белән расланган (Россия Федерациясе законнары нигезендә мөһергә ия булу йөкләмәсе билгеләнгән очракларда) һәм вәкаләтле зат имзасы белән таныкланган (юридик затлар өчен) яки үз имзасы белән таныкланган (индивидуаль эшмәкәрләр һәм физик затлар өчен) төзәтүләрдән тыш, бозып төзәтүләр һәм төзәтүләр рөхсәт ителми. Заявканың барлык битләренә саннар куелган булырга тиеш. Документларның күчермәләре шуңа вәкаләтле зат имзасы (юридик затлар өчен) һәм гариза бирүче мөһере (Россия Федерациясе законнары нигезендә мөһергә

ия булу йөкләмәсе билгеләнгән очракларда) белән таныкланган яки үз имзасы белән таныкланган (индивидуаль эшмәкәрләр һәм физик затлар өчен) булырга тиеш. Заявка беркетелгән, шуңа вәкаләтле зат имзасы (юридик затлар өчен) һәм гариза бирүче мөһере (Россия Федерациясе законнары нигезендә мөһергә ия булу йөкләмәсе билгеләнгән очракларда) белән таныкланган яки үз имзасы белән таныкланган (индивидуаль эшмәкәрләр һәм физик затлар өчен), заявканың икенче ягында битләрнең гомуми саны күрсәтелгән булырга тиеш. Заявканы әзерләү буенча барлык чыгымнарны гариза бирүче күтәрә.

2.4. Заявка составында кирәкле документлар булмау, әлеге Тәртипнең 2.3 нче пунктында билгеләнгән заявканы рәсмиләштерүгә таләпләрне бозу яисә гариза бирүче тапшырган документларда гариза бирүченең әлеге Тәртипнең 1.4 нче пунктында каралган шартларны үтәвен раслый торган мәгълүматлар булмау субсидия бирүдән баш тарту өчен нигез булып тора.

2.5. Гариза бирүченең (юридик затның, индивидуаль эшмәкәрнең) әлеге Тәртиптә билгеләнгән таләпләргә туры килү-килмәве түбәндәге документлар нигезендә билгеләнә:

дәүләт теркәве турында шаһәдәтнамә;

салым органында исәпкә кую турында шаһәдәтнамә.

Вәкаләтле оешма әлеге документларны Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән тәртиптә ала.

Гариза бирүче әлеге пунктта күрсәтелгән документларны Вәкаләтле оешмага үз инициативасы белән кертергә хокуклы.

2.6. Тапшырыла торган мәгълүматларның дөреслеге өчен гариза бирүчеләр Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылык тота.

## 3. Заявкаларны кабул итү һәм карап тикшерү

3.1. Заявкаларны кабул итү чоры Вәкаләтле оешма карары белән билгеләнә. Әлеге Тәртип, аларны бу Тәртип нигезендә тутыру кирәк булган документлар формалары, шулай ук заявкаларны кабул итү чоры турында мәгълүмат Вәкаләтле органның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында заявкаларны кабул итә башлаган көнгә кадәр эш көннәрендә исәпләнә торган 3 көн эчендә урнаштырыла.

Әлеге Тәртипнең 1.2 нче пунктында күрсәтелгән, бирелгән бюджет ассигнованиеләрен тулысынча бүлгән очракта, Вәкаләтле оешма тарафыннан заявкаларны кабул итү гамәлгә ашырылмый. Моның турында мәгълүмат Вәкаләтле органның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында Вәкаләтле оешманың тиешле карарын раслаган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 3 көн эчендә урнаштырыла.

Вәкаләтле оешма түбәндәге очракларда заявкаларны яңадан кабул итә башлый:

агымдагы елда чараны тормышка ашыруга Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән өстәмә бюджет ассигнованиеләре бирү;

субсидия алудан баш тарту (шәхси гариза яки әлеге Тәртипнең 3.7 нче пункты таләпләре нигезендә).

Заявкаларны яңадан кабул итә башлау турында мәгълүмат Вәкаләтле органның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында заявкаларны яңадан кабул итә башлаган көнгә кадәр 3 эш көненнән дә соңга калмыйча урнаштырыла.

3.2. Заявка кертелгән көнне Вәкаләтле оешма тарафыннан заявкаларны теркәү журналында (алга таба – журнал) теркәлә.

3.3. Заявкалар журналда теркәлгән көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә Вәкаләтле оешма тарафыннан әлеге Тәртип таләпләренә туры килү-килмәвенә тикшерелә, һәм Вәкаләтле оешма аларның таләпләргә туры килүе яки туры килмәве турында карар чыгара. Карап тикшерү һәм карар кабул итү тәртибе Вәкаләтле орган тарафыннан билгеләнә.

Вәкаләтле оешма әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән тикшерү вакыты чыккан көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 3 көн эчендә заявканы тикшерү нәтиҗәләре турында гариза бирүчегә тиешле рәвештә хәбәр итә.

3.4. Заявка әлеге Тәртип таләпләренә туры килмәгән очракта, гариза бирүче тапшырган документларын Вәкаләтле оешмадан соратып алырга хокуклы.

3.5. Заявканың әлеге Тәртиптә каралган таләпләргә туры килүе яки килмәве турында кабул ителгән карар нәтиҗәләре буенча, Вәкаләтле орган субсидия бирү турында яки субсидия бирүдән баш тарту хакында карар кабул итә. Карар кабул итү тәртибе Вәкаләтле орган тарафыннан билгеләнә.

3.6. Аларга карата субсидия бирү турында уңай карар кабул ителгән гариза бирүчеләр тиешле карар кабул ителгән көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә Вәкаләтле орган раслаган форма буенча килешү төзүне тәэмин итәләр.

3.7. Гариза бирүче әлеге Тәртипнең 3.6 нчы пунктында күрсәтелгән таләпне үтәмәгән очракта, субсидия бирү турында карар гамәлдән чыккан дип санала.

Субсидия бирү турындагы карарны гамәлдән чыгару процедурасы Вәкаләтле орган карары нигезендә гамәлгә ашырыла.

3.8. Килешү субсидия бирү өчен нигез булып тора. Килешүдә субсидиянең күләме, максатчан билгеләнеше, субсидия алучының субсидия бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәвенә Вәкаләтле орган һәм дәүләт финанс тикшерүе органнары тарафыннан тикшерүләр үткәрүгә субсидия алучының ризалыгы күздә тотыла. Шул ук вакытта субсидиянең күләме әлеге Тәртипкә теркәлгән кушымта нигезендә транспорт чарасы төренә бәйле рәвештә билгеләнә.

3.9. Субсидияләр, бюджет ассигнованиеләре күчү вакытларын исәпкә алып, килешү төзегән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә Вәкаләтле оешманың казначылык органнарында ачылган шәхси исәбеннән субсидия алучының хисап исәбенә акча күчерү юлы белән бирелә.

3.10. Вәкаләтле оешмага заявкада күрсәтелгән, дөреслеккә туры килмәгән мәгълүматлар тапшырган очракта, субсидия алучы Вәкаләтле оешманың тиешле таләбен алган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә бирелгән субсидияләр Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиеш.

Субсидияләр бирү турындагы килешүләр белән күздә тотылган очракларда, хисап финанс елында файдаланылмый калган субсидияләр хисап елыннан соң килә торган елның 1 февраленә кадәр Татарстан Республикасы бюджеты керемenә кире кайтарылырга тиеш.

3.11. Әлеге Тәртипнең 3.10 нчы пунктында күрсәтелгән вакытларны бозган очракта, субсидия алучыдан субсидия акчасын кайтарту өчен Вәкаләтле орган әлеге Тәртипнең 3.10 нчы пунктында күрсәтелгән вакытлар чыккан көннән календарь көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә субсидияне Татарстан Республикасы бюджеты керемендә кире кайтару буенча Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән тәртиптә чаралар күрә.

3.12. Вәкаләтле орган һәм дәүләт финанс тикшерүе органнары субсидия алучыларның субсидияләр бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүләрен тикшерүне Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашыра.

3.13. Гариза бирүче Вәкаләтле орган һәм Вәкаләтле оешма вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмавына) Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән тәртиптә шикаять бирергә хокуклы.

F:\KARAR\2016\90_1.doc

Татарстан Республикасында транспорт чараларын газ-мотор ягулыгына күчерүне гамәлгә ашырган юридик затларга, индивидуаль эшмәкәрләргә һәм физик затларга чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә кушымта

**Татарстан Республикасында транспорт чараларын газ-мотор ягулыгына күчерүне гамәлгә ашырган юридик затларга, индивидуаль эшмәкәрләргә һәм физик затларга чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган субсидиянең транспорт чарасы төренә бәйле рәвештә күләме**

| Т/с | Транспорт чарасының төре | Транспорт чарасы-ның кате-го-риясе | Транспорт чарасының тасвирламасы | Субсидия күләме |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 1. | Җиңел автомобиль | B; B1 | Рөхсәт ителгән максималь авырлыгы 3 500 килограммнан артмаган һәм утыру өчен билгеләнгән урыннар саны, йөртүче урыныннан тыш, сигездән артык булмаган автомобиль; рөхсәт ителгән максималь авырлыгы 750 килограммнан артмаган тагылма тоташтырылган «B» категорияле автомобиль; рөхсәт ителгән макси-маль авырлыгы 750 килограммнан артык булган, ләкин, транспорт чаралararының әлеге составының рөхсәт ителгән максималь авырлыгы 3 500 килограммнан артмый дигән шартта, йөкләнештән башка автомобиль авырлыгыннан артмаган тагылма тоташтырылган «B» категорияле автомобиль | транспорт чарасын газ-мотор ягулыгына күчерү кыйммәтенең 30%, әмма 27 000 сумнан артык түгел |
| 2. | Җиңел йөк (кече коммерция) автомобиле | B; B1 | Рөхсәт ителгән максималь авырлыгы 3 500 килограммнан артмаган һәм утыру өчен билгеләнгән урыннар саны, йөртүче урыныннан тыш, сигездән артык булмаган автомобиль; рөхсәт ителгән максималь авырлыгы 750 килограммнан артмаган тагылма тоташтырылган «B» категорияле автомобиль; рөхсәт ителгән макси-маль авырлыгы 750 килограммнан артык булган, әмма, транспорт чаралararының әлеге составының рөхсәт ителгән максималь авырлыгы 3 500 килограммнан артмый дигән шартта, йөкләнештән башка автомобиль авырлыгыннан артмаган тагылма тоташтырылган «B» катего- | транспорт чарасын газ-мотор ягулыгына күчерү кыйммәтенең 25%, әмма 40 000 сумнан артык түгел |

<table>
<tr><th>1</th><th>2</th><th>3</th><th colspan="2">4</th><th>5</th></tr>
<tr><td></td><td></td><td></td><td colspan="2">рияле автомобиль;<br>йөртүче урынынnan тыш, күп дигәндә сигез утыру өчен билгеләнгән урыны булган, пассажирларны йөртү өчен транспорт чарасы (6 метрга кадәр озынлыктагы аеруча кечкенә, кечкенә)</td><td></td></tr>
<tr><td>3.</td><td>Йөк автомобиле</td><td>C</td><td colspan="2">«D» категорияле автомобильләрдән тыш, рөхсәт ителгән максималь авырлыгы 3 500 килограммнан арткан, йөк күтәрүчәнлеге 12 тоннага кадәр булган автомобиль (шул исәптән комбинацияләнгән юл техникасы)</td><td>транспорт чарасын газмотор ягулыгына күчерү кыйммәтенең 20%, әмма 76 000 сумнан артык түгел</td></tr>
<tr><td rowspan="2">4.</td><td rowspan="2">Автобус</td><td>D</td><td>4.1. Пассажирларны йөртү өчен транспорт чарасы (6,0 – 8,0 метрлы озынлыктагы һәм гомуми сыйдырышлыгы 40 урынга кадәр булган уртачалар)</td><td rowspan="2">Пассажирларны йөртү өчен каралган һәм, йөртүче урынынnan тыш, сигездән артык утыру өчен билгеләнгән урыны булган автомобиль; тагылма тоташтырылган «D» категорияле автомобиль</td><td>транспорт чарасын газмотор ягулыгына күчерү кыйммәтенең 20%, әмма 42 000 сумнан артык түгел</td></tr>
<tr><td>D</td><td>4.2. Пассажирларны йөртү өчен транспорт чарасы (8,0 – 9,5 метрлы озынлыктагы һәм гомуми сыйдырышлыгы 65 урынга кадәр булган зурлар һәм 100 урынга кадәр булган аеруча зурлар)</td><td>транспорт чарасын газмотор ягулыгына күчерү кыйммәтенең 20%, әмма 74 000 сумнан артык түгел</td></tr>
<tr><td>5.</td><td>Магистраль тягач</td><td>CE; C1E</td><td colspan="2">Тагылма тоташтырылган «C» категорияле автомобиль</td><td>транспорт чарасын газмотор ягулыгына күчерү кыйммәтенең 15%, әмма 73 500 сумнан артык түгел</td></tr>
</table>